ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 февраль 2026ел № 1621

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, алар тарафыннан арендага алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4419 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2022 елның 1 августындагы 3860 номерлы, 2023 елның 31 августындагы 7913 номерлы, 2023 елның 1 декабрендәге 11683 номерлы, 2025 елның 30 гыйнварындагы 555 номерлы, 2025 елның 7 маендагы 3315 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендага алына торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны тормышка ашырганда, алар тарафыннан арендага алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5.2 пунктына, түбәндәге эчтәлектәге 3 пунктча өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«3) Башкарма комитетка шәхсән яки почта элемтәсе аша кәгазьдә. Почта элемтәсе аша җибәрелгәндә, гариза һәм теркәлә торган документлар билгеләнгән тәртиптә раслана.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов